КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1256

2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында

Түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын тәэмин итү максатларында һәм «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре турында» 2018 елның 10 декабрендәге 1506 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Программа кысаларында 2019 елда күрсәтелгән медицина хезмәтләре өчен исәп-хисапларны тәмамлау 2020 елның 15 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла;

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлек турындагы хисап законнар нигезендә билгеләнгән тәртип һәм формалар нигезендә һәм Программаны раслаган көннән алып 14 көн эчендә -тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары тапшырыла;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турында тариф килешүе төзү;

өстенлекле бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган тарифларны һәм медицина ярдәме өчен түләү тәртибен эшләү һәм вәкаләтле органга раслауга тапшыру;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен файдаланып, рәсми сайтка медицина ярдәме өчен түләүгә билгеләнгән программалар һәм тарифлар урнаштыру;

2019 елның 15 февраленә кадәр «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә медицина оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлегенең килешенгән планнарын тапшыруны тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондына күрсәтелгән максатларга «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы һәм «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарында каралган» бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Программаны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

4. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин